"Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы 5 нче гимназиясе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе"

Сыйныф сәгате

Тема: «Равил Сәйфетдинов иҗатына нигезләнеп туган якны өйрәнү буенча сыйныф сәгате"


Эшнең авторы:
Николаева Лэйлэ Камил кызы
Инглиз теленнэн укытучы
МБОУ «Гимназия 5 ЗМР РТ»


ЯшелҮзән

**Катнашучының гаризасы**

| | |
|---|---|
| Ф.И.О. участника / Катнашучының Ф. И. А.и. | Николаева Лэйлэ Камил кызы |
| Тема работы / Эшнең темасы | « Равил Сәйфетдинов иҗатына нигезләнеп туган якны өйрәнү буенча сыйныф сәгате" |
| Почтовый адрес места жительства участника / Катнашучының өй адресы | leylanikzal@mail.ru |

**«Безнең як-Тау Ягының бөек шәхесе»**

**«Мөгаллим дә, шагыйрь дә булган сәләтле шәхес»**

Яшел Үзән районының 5 нче гимназиясендә татар, рус һәм башка милләт балалары укый. Һәр дүшәмбе көнне "Мөһим сәйләшүләр" сыйныф сәгатләре кысаларында укучыларда патриотик тәрбия бирүгә зур урын бирелә. Шул исәптән туган як эдиплэренең әсәрләренә кызыксыну уяту, татар адабиятына мәхәббәт, хөрмәт тербияләү максатыннан төрле чаралар, ачык дареслар уткәрелә.

**Тема:** « Равил Сәйфетдинов иҗатына нигезләнеп туган якны өйрәнү буенча сыйныф сәгате"

**Максат:** 1. Укучыларны үзебезнең як шагыйре Равил Сайфетдинов тормышы һәм иҗаты белан таныштыру;

2. Туган тел, туган як белән горурлану хисе уяту, аның матурлыгын тоярга өйрәтү, миллилек тәрбияләү; Россиядә, Татарстанда яшәүчемилләтләрнең дуслыгына хөрмәт булдыру.

3.Туган якка карата ярату хисен уяту.

**Җиһазлау:** Равил Сәйфетдинов портреты, әсәрләреннән төзелгән китап күргәзмәсе, мультимедиа, әсәрләренә укучылар ясаган рәсемнәр, матбугат материаллары.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру өлеше.**

**1 нче алып баручы.** Исәнмесез, кадерле укытучыларыбыз һәм дусларыбыз, килген кунаклар!

**2 нче алып баручы.** Һәр төбәкнең үзенең күренекле шәхесләре була. Алар турында горурланып сөйләнелә, кылган гамәлләре хөрмәтләнә, яшь буынны да шулар үрнәгендә тәрбияләү максаты куела. Бүген дә без «Безнең як-Тау Ягының бөек шәхесе» дип исемләнгән сыйныф сәгатебезне Яшел Үзән ягы шагыйре Равил Сайфетдиновка багышланган шигырь кичәбезне башлыйбыз.

**II. Төп өлеш.**

**3 нче алып баручы.** Равил Гарәфетдин улы Сәйфетдинов 1938 нче елның 14 нче октябрендә Яшел Үзән районының Мулла Иле авылында туган. Урта мәктәпне бетергәч, 1965-1961 нче елларда Казан дәүләт унивеситетында укыган.

**1 нче алып баручы.** 1961-1963 нче елларда Самара өлкәсендәге Гали урта мәктәбендә укытучы булып эшләгән.

**2 нче алып баручы.** 1963-2007 нче елларда берөзлексез Мулла Иле мәктәбендә хезмәт иткән: авыл мөгаллиме буларак, татар теле һәм әдәбияты, рус теле һәм әдәбияты, немец теле, гарәп теле, дин тарихы предметларын укыткан.

**3 нче алып баручы.** 1968-1970 нче елларда – завуч, 1971-2000 нче елларда мәктәп директоры булган.

**1 нче алып баручы.** Ул – Россиянең мәгариф отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы, СССР мәгариф министрлыгының Мактау Грамотасы белән бүләкләнгән. Республика матбугатында педагогикхезмәтләре, әдәби әсәрләре әле дә басылып тора.

**2 нче алып баручы.** Равил хәзрәт Сәйфетдин 2005 нче елдан алып Мулла Иле мәчете имам- хатыйбы вазифаларын башкара.

**3 нче алып баручы.** 2017 нче елда рухи-әхлакый традицияләрне үстерүдә, тынычлык һәм конфессияара килешүне ныгытуда зур көч куйганы өчен Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнә.

**1 нче алып баручы.** 2018 нче елның 10 нчы февралендә вафат.

**2 нче алып баручы.** Без буген сезне Равил Сайфетдиновның шигырьләре белән таныштырырбыз.

**3 нче алып баручы.** Равил Сайфетдинов узенең туган ягын,туган авылын табигатьне бик яраткан. Анын Мулла иле авылы, безнең Яшел Үзән шәһәре, табигать турында язган шигырьләре бик куп. Хэзер без аларнын кайберларен сезгә сәнгатьле итеп сөйләп курсәтербез.

**Яшел Узән!**

Мэчетлэрен гузэл бер-берсеннэн,
Нур сибэлэр бетен шэһэргэ.
Зэңгэр куккэ ашкан манаралар
Көч бирэлэр җирдэ яшэргэ
Мин шуларга карап сөенэм дэ,

Җылы хислэр били куңелне.
Тоела мина: гуя син яшь тугел,
Бик борынгы шэһэр шикелле.
Килэсендер Болгар чорыннан ук,
Менэ монда — Идел урендэ
Торасыңдыр гасырларны кочып,
Тарих мина шулай куренэ.
Район өчен узэк булсан да син,
Минем очен — мәркәз, башкала.
Юкка гына өзгэлэнми узэк,
Кимсеткэндэ сине башкалар.
Бэйрэм хисе калды гомерлеккә,
Мин бүген дә, шулай ашкынып,
Сиңа килэм,гүзэл Яшел Үзэн,
Бар хыялны чынга ашырып.

**1 нче алып баручы.** Равил ага Сайфетдинов өчен дә үзенең туган авылы, мәркәзе дип саналган безнең Яшел Үзән шәһәребез дә җанына рәхәтлек бирә торган гүзәл табигате, шифалы сулары бик тә газиз.

**2 нче алып баручы.** Әйе шул! Туган як, туган туфрак, туган якның сихри табигате... Шундый кадерле, якын һәм назлы бу сүзләр. Һәр якның матурлыгы, гүзәллеге иҗат әһелләре әсәрләре аша әдәбиятка үтеп керә, башкаларны да таң калдыра, сокландыра.

**3 нче алып баручы.** Иҗатының беренче чорын тәшкил иткән, студент елларында язылган шигырьләренең  үзәгендә дөнья бизәкләренә мәхәббәт, сөю-сөелү белән сынау, «аның» килүен көтү, юксыну, шикләнү... Зөһрә, Ләйлә һәм Мәҗнүн кебек лирик геройлар шигырьләрендә чагылыш ала.

Һич кенә дә ким түгел.
Син янасың тиңсез йолдыз булып,
Җырланмаган җырым иясе.
----------------------------------------------
Сине үбә зәңгәр күк кояшы
Дала җиле сыйпый кадерләп.
(«Син янасың...», 1959)
Сине усал һәм тәкәббер диләр,
Артык горур диеп сөйлиләр.
(«Сине усал...», 1959)
«Мәңгелек кыз» шигыренә иркәләнеп чытыкланулары, үзен иркен-ирекле тотуы белән
Такташның Алсуы килеп кергәндәй була.
Ул кызыйга һәркем үлеп гашыйк,
Әллә ние белән сөйдерә.
Ул үзе дә барсын – яшен-картын
Коча-үбә, уйлап тормый шартын,
Чәчәк биреп китә – исертә,
Йөрәкләргә серле көч кертә.
(«Мәңгелек кыз», 1959)
Син тормышның үзе кебек чибәр,
Үзе кебек чуар гүзәлем.
(«Сине усал...»)

**1 нче алып баручы.** Туган авылында мөгаллимлек эшенә, шук балалар, һәркайсы үзен тиешле бәясен алмаган шәхес санаган укытучылар дөньясына кереп чумып,
гаиләдә балалар үстерү мәшәкатьләре өстенә өелеп төшкәч, шигърияте дә күзгә күренеп үзгәрә.

Соң килдең син миңа, Акыл,
Кайда йөрдең яшь чакта?
Синнән башка мине йөрәк
Тилертте төрле якка.

Соң килдең син миңа, Акыл,
Рәшәләр кая киткән?
Алсу, алсу дигәннәрем
Алсу булмаган икән.
 ***
Кеше җирнең бөтен матурлыгын
Үзенә җыйган бөек баласы.
Ул –тән генә, матди генә түгел,
Шуңа кыен кеше буласы.
(«Кеше – бөек», 1969)
 ***
Кеше үзе белми
Ак биләүле чагын.
Ак кәфенле чагын
Белми кала тагын.
 ***
Вакыт ага күзгә күренмичә,
Ага галәм аша, йолдызларның
Берсен кабызып, берсен сүндереп,
Вакыт ага таулар аша,
Вакыт ага минем тәнем аша.
(«Вакыт ага». 2002)

**2 нче алып баручы.** Равил ага Сайфетдинов бөтен көчен куеп, татар, рус, немец (немец телен ул камил белгән) телләрен укыта. Шушы телләр буенча бик күп методик әдәбият туплый. Шул телләрне үзе берөзлексез чагыштырып өйрәнә. Аның бу өйрәнүе гомер буена китә, хоббиена әйләнә. Ул Тукай, Такташ, Илдар Юзеевларны тәүлекләр буенча русча сөйли ала,Пушкин, Евтушенколарны яттан сөйләп кенә калмый, татарчага тәрҗемә итә, Гёте, Гейнеләрнең шигырьләрен дә яттан белә һәм немецчәдән татарчага тәрҗемә дә итә. Ул күп мәртәбәләр Мулла Иле мәктәбендә дәрес биргәндә үзешчән нәфис сүз осталарының республика конкурсында катнаша һәм берничә мәртәбә бөтенсоюз лауреаты исемен дә яулый.

**Иң мөкатдәс нәрсә-эш**

Ялган шөһрәт, даннар белән түгел,
Эшең белән калдыр эзеңне.
Эзләп тапсын кеше мәхәббәте
Тормыш эчләреннән үзеңне.

**3 нче алып баручы** Укытучы булып эшләү дәверендә шагыйрь әдәп-әхлак, тәрбияви-мәгърифәти мәсьәләләрне күбрәк игътибар үзәгенә ала.

**Хәерле юл, яңа мәктәп!**

И авылым, чал тарихлы яшь авылым!Гел
нурлана, хозурлана яшәү юлың. Менә
тагын бер хыялың ашты чынга:Яңа
мәктәп басты кояш каршысына.
Сабыйларың – синең нурлы киләчәгең,Мул
җимешләр өмет итәр ал чәчәгең – Үссен
әйдә заманага лаек булып,
Илгә бәхет китерерлек белем алып.
Хәерле юл, мәктәп – киләчәккә карап,
Шатлык төяп сәфәр чыккан кораб!
Бар яктырып яңа гүзәл заманнарга
Һәм бездән дә сәлам тапшыр син аларга.
(1986)

**1 нче алып баручы.** Равил Сайфетдинов әсәрләрендә шулай ук әти-әнигә дә дан яңгырый

**Эни**

Бер мизгелдә сирень, хәлсезләнеп,
Койды чәчәген.

Нигә, әни, рәхәт заманадаБик
аз яшәдең?
**Гомерем буе мин әтине эзлим**
Гомерем буе мин әтине эзлим
Барлык почмагыннан дөньяның.
Миллион-миллион кабер ташларыннан
Исемнәрен тапмыйм мин аның.
**III Йомгаклау.**

**2 нче алып баручы.** Равил абыйның шигырьләре – ул туган ягыбызның, халкының күңел көзгесе. Шигырьләрендә шагыйрь җаны табигать җаны белән берләшә. Туган җирнең матурлыгын бары тик аның табигате аша гына күз алдына китерергә мөмкин. Табигать – Равил аганың илһам, яшәү чыганагы, яшәеш үрнәге. Шигырьләрендә шагыйрь күңеле язын кошлар белән туган якка кайта, җәен сандугачтай сайрый, көзен сагышларын кыр казының канатына элеп җибәрә, ә кышын ап-ак кар булып ява.

**3 нче алып баручы**. Яшәешебезгә, телебезгә инкыйраз янаган XXI гасыр башында дин әһелләре арасында Р. Сәйфетдин кебек олы тормыш мәктәбе узган, татар телен, әдәби мирасыбызны бөтен нечкәлекләре белән тойган, милләтенең яшәеше өчен җан атып йөргән шәхесләр күбрәк булырга тиеш дип уйлыйм.

Равил ага Сайфетдиновның максаты- сезгә туган якны, Ватанны яратырга, сакларга. Укучылар, үзебезнең як табигате сулышын, туфрагының җылысын тоеп, яшәүнең тәмен һәм мәгънәсен сизеп яшик. Ә без бу серләргә бары тик якташларыбыз иҗаты белән кызыксынганда, тарих, әдәбият дәрьясында йөзгәндә генә төшенә алабыз.

**1 нче алып баручы**. Шуның белән сыйныф сәгатебез тәмам. Игътибар белән карап утыруыгыз, катнашуыгыз өчен рәхмәт.

Кичебезне Р.Сәйфетдиновның «Бәхет үзәне» дигән шигыре белән тәмамлыйбыз!

Татар иленең киң кочагында
Санап бетергесез авыллар.
Шулар арасында әни кебек Газиз
булган туган авыл бар.
Бер ягында тезмә-тезмә таулар,
Шунда менеп түбән карыйм даБар
күңелем китә иркенәеп, Мин
берьюлы күрәм барын да:
Шундый биек зәңгәр күк гөмбәзе.Бик-
бик ерак күксел офыклар.
Галәмәт киң иркен бу үзәндә Мәңгелек
ямь, бетмәс шатлык бар.
Урманнардан ары – карт талларның
Кочагында гүзәл Мулилем.
Гомерлеккә яшәү көче биргән, Илһам
биргән җирем шул минем.(1980)

Милли төбәк компоненты кулланып үткәрелгән дәресләр, класстан тыш чаралар турындагы мисалларны тагын китерергә мөмкин булыр иде.Чөнки Яшел Үзән районы күренекле шәхесләргә бик бай як.Үсеп килүче яшь буынны алар үрнәгендә дә тәрбияләү- район мөгаллимнәре алдында торган төп бурычларның берсе һәм алар аны гамәлгә ашыруда армый-талмый эшлиләр.

**Кулланылган әдәбият**


1. Сәйфетдинов Р.Г. Аксакал язмалары. Шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләрҗыентыгы.// Казан, 2017.
2. Сәйфетдинов Р.Г. Кичке шәфәкъ. Шигырьләр җыентыгы.// Казан, 2001.
3. Сәйфетдинов Р.Г. Мулла Иле моңнары. Шигырьләр, хикәяләр, мәкаләләрҗыентыгы.// Казан, 2010.
4. Хәмидуллина Р.Г., Габделхәева Г.Б. Илһам биргән җирем.// Казан, 2020.